| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| --- | --- |
| **Исполнительный комитет поселка городского типа Уруссу Ютазинского муниципального района** | **Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты** |
| 423950, п.г.т. Уруссу<br>ул. Пушкина, 38<br>тел. 2-61-50<br>2-92-40 | 423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы<br>Пушкин урамы, 38<br>тел. 2-61-50<br>2-92-40 |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 35 20.10.2016г.

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогын җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында"

2006 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 27.07.2010 ел, № 190-ФЗ Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына таләпләр, аларның тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карары белән расланган «Җылылык белән тәэмин итү схемаларын эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр» нигезендә, 2016 елның 25 октябрендәге Урыссу шәһәр тибындагы поселогын җылылык белән тәэмин итү схемасын актуальләштерү буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Урыссу шәһәр тибындагы поселогын 2035 елга кадәр җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын расларга (1 нче кушымта).
2. Расланган көннән алып 15 календарь көн эчендә җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында тулы күләмдә урнаштырырга һәм «Ютазинская новь» («Ютазы таңы») газетасында җылылык белән тәэмин итү схемасын рәсми сайтта урнаштыру турында мәгълүмат бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р. Ф. Вәдигуллин